# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында"**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында" 2004 елның 24 мартындагы 25-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (IV өлеш); 2005, №12 (I өлеш); 2007, №4; 2010 № 6 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяга түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәргә:
"Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлары өчен" медале.";

2) түбәндәге эчтәлекле $IV^2$ бүлек өстәргә:

"$IV^2$ бүлек. **"ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕ ҮСТЕРҮДӘГЕ КАЗАНЫШЛАРЫ ӨЧЕН" МЕДАЛЕ**

$18^4$ статья. **"Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлары өчен" медале турында нигезләмә**

"Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлары өчен" медале белән гражданнар Татарстан Республикасында җирле үзидарәне оештырудагы һәм үстерүдәге, җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттырудагы, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне, тарихи һәм башка җирле традицияләрне исәпкә алып, халык мәнфәгатьләреннән чыгып хәл итүдәге зур казанышлары өчен бүләкләнә.

$18^{5}$ статья. **"Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлары өчен" медаленең тасвирламасы**

"Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлары өчен" медаленең тасвирламасы Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

$18^{6}$ статья. **"Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлары өчен" медален тагып йөрү**

"Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлары өчен" медале күкрәкнең сул ягында тагып йөртелә. Бүләкләнүченең башка медальләре булганда, "Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлары өчен" медале "Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан" медаленнән соң урнаштырыла.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.М. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 31 декабре
№ 136-ТРЗ